**МИНИСТЕРСТВО ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

09.11.2015 № 821

г.Казань

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 30 ноябрендә теркәлде, № 3007

Татарстан Республикасы Хезмәт,
халыкны эш белән тәэмин итү
һәм социаль яклау министрлыгының
"Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә
түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын
раслау турында" 19.11.2014, № 634 боерыгы белән
расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә
түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

**Боерык бирәм:**

Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының "Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында" 19.11.2014, № 634 боерыгы белән расланган Торакка һәм коммуналь хезмәтләр күрсәтүгә түләү өчен субсидия-ташлама билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.2 пунктның 32 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"32) пенсияләре "Иминият пенсияләре турында", "Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында" һәм "Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында" Федераль законнар нигезендә билгеләнгән яки башка нигезләр буенча пенсия алучы яисә "Иминият пенсияләре турында" Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә чыгу хокукы биргән яшькә җиткән, эшләгән (хезмәт иткән) өчен гомерлеккә акча алучы хезмәт ветераннары";

1.2 пунктның 35 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“35) пенсияләре “Иминият пенсияләре турында”, “Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында” һәм “Россия Федерациясендә дәүләт пенсия тәэминаты турында” Федераль законнар нигезендә билгеләнгән, яки башка нигезләр буенча пенсия алучы яисә “Иминият пенсияләре турында” Федераль закон нигезендә картлык буенча пенсиягә чыгу хокукы биргән яшькә җиткән, эшләгән (хезмәт иткән) өчен гомерлеккә акча алучы “Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләре турында” Татарстан Республикасы Законы белән гамәлгә куелган Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре белән бүләкләнгән затлар;”;

1.4.2 пунктның 1 пунктчасында “1.5” цифрларын “2.1” цифрларына алмаштырырга;

1.5 пунктның унбишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“Татарстан Республикасында яшәүчеләрнең аерым категорияләренә акчалата түләүләр, пособиеләр, субсидияләр һәм стипендияләр бирү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында” 17.12.2004 ел, № 542 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (алга таба – № 542 ТР МК карары) (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнарының норматив актлары җыентыгы, 2005, № 1-2, 0018 ст., кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);”;

“Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасының 2.1 пунктындагы унынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“№ 542 ТР МК карарының 2 п.;”;

2.5 пунктның “Стандартка карата таләпләр эчтәлеге” графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Субсидия-ташлама бирү турында бу Регламентка 1 нче кушымта нигезендәге форма буенча гариза.

2. Законлы вәкилләрнең яки ышанычнамә нигезендә вәкаләт бирелгән затларның торак-коммуналь хезмәтләргә түләү буенча социаль ярдәм чараларына законнарга тәңгәл рәвештә хокукы булган гражданнарның мәнфәгатьләреннән чыгып эш итүгә вәкаләтләрен раслаучы документлар күчермәләре.

Документлар күчермәләре Россия Федерациясе законнары нигезендә расланмаган очракта төп нөсхәләрен күрсәтеп тапшырыла һәм Үзәк бүлеге белгече тарафыннан раслана.

Гариза бирүче, мөрәҗәгать иткәндә, шәхесен таныклаучы документ, банкта яки башка кредит учреждениесендә ачылган лицевой счет реквизитларын, шулай ук, гамәлдәге законнар белән күздә тотылган очракларда, гражданинның субсидия-ташламага хокукын раслаучы документ күрсәтә.

Гаризаны почта аша җибәргәндә, аңа кушып бирелә торган документлар күчермәләре закон белән билгеләнгән тәртиптә расланган булырга тиеш.”;

“Дәүләт хезмәте күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив акт” графасының 2.5 пунктындагы беренче абзацта “1.2” цифрларын “2.2” цифрларына алмаштырырга.

**Министр** **Э.Ә.Зарипова**